РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 12 2019 ел №991

2019-2020 елларда Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен
уздыру чорында Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы территориясендә
янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру барышында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген янгыннан саклау, физик һәм юридик затларга, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар кабул итте:

1. Билгеләргә:

2019 елның 20 декабреннән 2020 елның 08 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертелүен;

махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда 1-3 куркынычлык классы булган пиротехник эшләнмәләрне (бенгаль утларыннан, “хлопушка”лардан тыш) түбәндәге ара чикләрендә урнашкан территорияләрдә куллануны тыюны билгеләргә:

сәнәгать объектлары, транспорт инфраструктурасы, ягулык-энергетика комплексы чикләреннән 500 метр ераклыкта;

торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы, кешеләр күп була торган объектлар чикләреннән 50 метр ераклыкта.

2. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең һәм Татарстан Республикасы Ютазы районы эчке эшләр министрлыгының Баулы һәм Ютазы муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын исәпкә алырга;

Кешеләр күпләп җыела торган Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен үткәрү урыннарына профилактик тикшерү үткәрергә;

Ютазы районы эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләре белән берлектә моның өчен билгеләнмәгән сәүдә урыннарында пиротехник эшләнмәләрне ачыклау һәм сатуны тыю, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тиешле сертификатлары булмаган продукцияне сатуны тыю буенча рейдлар оештырырга һәм уздырырга;

пиротехник эшләнмәләрне кулланганда, шул исәптән кертелә торган тыюларны үтәгәндә, оешмалар һәм гражданнар тарафыннан янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне контрольдә тоту буенча чаралар үткәрүдә катнашырга.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

2009 елның 22 декабрендәге “Пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында” 1052 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган пиротехника әйберләрен таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итүләрен;

янгын сүндерүгә яраклаштырылган техника белән тәүлек буе ирекле янгын сүндерү хезмәте әгъзаларының дежурлыгын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга;

янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

махсус җиһазландырылган мәйданчыклардан тыш пиротехник эшләнмәләрне кулланырга ярамаганлыгы турында халыкка хәбәр итәргә һәм куркынычсызлык таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга;

кирәк булган очракта, тиешле территорияләрдә пиротехник эшләнмәләрне куллануны тыюны билгеләргә .

4. Урыссу ш.т.п. территориясендә «Яңарыш» паркы артындагы куркынычсыз зонада, Аксакүл авылына таба «Уруссу-Каразирек» автоюлы артында пиротехник эшләнмәләрне куллану өчен урын оештырырга. Тиешле мәйданчыкны пиротехника эшләнмәләрен кулланганда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат булган стенд, тиешле күләмдә беренчел янгын сүндерү чаралары белән җиһазландырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе А.Ә. Шафигуллин

Р.М. Мансуров
2-81-49